# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керүче Турай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«14» ноябрь 2025 ел № 15

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 ст., Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 4 октябрендәге 100 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында 2025 елның 14 ноябрендә узган гражданнар җыенында “2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә. 1 нче төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәрен, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, көндезге уку формасында укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнарны түләүдән азат итәргә һәм үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә Сез ризамы?” дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

“1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу; МТЗ-82.1 тракторы өчен чүмечле КУН сатып алу.)

2) Турай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү) .)

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Турай торак пунктының Крайняя, Тынычлык, Окольная, Совет урамнары буенча юл өслегендәге чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу; вак таштан соң юл өслеген тигезләү ( эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).)

4) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

5) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү)

6) Үзара салым акчаларының узган еллардагы калдыкларын юлларны кардан чистартуга тотарга.” ?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 307 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашучылар саны 219 кеше.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 219 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1.Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә. 1 нче төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәрен, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, көндезге уку формасында укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына срокллы хезмәткә чакырылган гражданнарны түләүдән азат итәргә һәм үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә Сез ризамы?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга :

2.1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу; МТЗ-82.1 тракторы өчен чүмечле КУН сатып алу)

2.2) Турай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү).)

2.3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Турай торак пунктының Крайняя, Тынычлык, Окольная, Совет урамнары буенча юл өслегендәге чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу; вак таштан соң юл өслеген тигезләү ( эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).)

2.4) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

2.5) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү)

2.6) Үзара салым акчаларының узган еллардагы калдыкларын юлларны кардан чистартуга тотарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Турай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы А.Т. Нуриев